СОВЕТ
ЯНГА - САЛСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Центральная, д.18, с. Янга-Сала,
Арский муниципальный район, 422011

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢАСАЛА
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Үзәк урам, 18 йорт, Яңасала авылы,
Арча муниципаль районы, 422011

Тел. (84366) 57-2-10, факс (84366) 57-2-10. E-mail: Yns.Ars@tatar.ru www.arsk.tatarstan.ru

**Яңасала авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**«03» август 2021 ел** **№ 29**

**«Яңасала авыл җирлеге Советы аппаратында һәм авыл җирлеге башкарма комитетының муниципаль хезмәт вазифаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру, шулай ук Яңасала авыл җирлеге Советы аппаратында һәм авыл җирлеге башкарма комитеты аппаратында муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру хакындагы Нигезләмәне раслау турында» Яңасала авыл җирлеге Советының 2014 елның 03 ноябрендәге 64 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында (2016 елның 18 апрелендәге 19 номерлы үзгәрешләр белән)**

«Цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законның аерым нигезләмәләрен гамәлгә ашыру чаралары турында» Россия Федерациясе Президентының 2020 елның 10 декабрендәге 778 номерлы Указы нигезендә Яңасала авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. «Яңасала авыл җирлеге Советы аппаратында һәм авыл җирлеге башкарма комитетының муниципаль хезмәт вазифаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру, шулай ук Яңасала авыл җирлеге Советы аппаратында һәм авыл җирлеге башкарма комитеты аппаратында муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру хакындагы Нигезләмәне раслау хакында» Яңасала авыл җирлеге Советының 2014 елның 03 ноябрендәге 64 номерлы карарына (2016 елның 18 апрелендәге 19 номерлы үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

6 пунктның 1.1 пунктындагы «в» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«в) үз чыгымнары, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының җир кишәрлеге, башка күчемсез мөлкәт объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр, акцияләр (оешмаларның устав (тупланма) капиталларындагы катнашу өлешләре, цифрлы финанс активлары, хисап чорында цифрлы валюта (1 гыйнвардан 31 декабрьгә кадәр) сатып алу буенча һәр алыш-биреш буенча чыгымнары турында белешмәләр, әгәр мондый алыш-бирешләрнең гомуми суммасы әлеге затның һәм аның хатынының (иренең) алыш-биреш башкарылганчы соңгы өч елдагы гомуми кеременнән һәм алыш-биреш башкарылган акчаларны алу чыганакларыннан артып китсә.»;

1.2. 13 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Муниципаль хезмәткәрнең, аның хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләр, шулай ук җир кишәрлеге, башка күчемсез мөлкәт объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр, акцияләр (оешмаларның устав (тупланма) капиталларындагы катнашу өлешләре, пайлар), цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта турында белешмәләр, әгәр алыш-биреш суммасы муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүче затның һәм аның хатынының (иренең) алыш-биреш кылуга кадәрге соңгы өч елдагы гомуми кеременнән артса, алыш-биреш башкарылырга тиешле акчаларны алу чыганаклары турында белешмәләр Арча муниципаль районының «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтында законнарда билгеләнгән тәртиптә урнаштырыла.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштыру һәм Арча муниципаль районы рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru) бастырып чыгару юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Яңасала авыл җирлеге
башлыгы А.И.Сафин

СОВЕТ ЯНГА-САЛСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ